**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Глава
Алькеевского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

Пер.Советский,44а, с.Алькеево
423309 тел. ( 885592) 37-4-23

**Alk.Azn@tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл жирлеге
советы
БАШЛЫГЫ

Совет тыкрыгы, 44а
Әлкәй авылы, 423309
тел. (885592) 37-4-23
**Alk.Azn@tatar.ru**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**15.10.2025 ел** **№2**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Әлкәй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елның 29 октябренә 18.00 сәгатътә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегене Әлкәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Әлкәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы -Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2025 елның 29 октябрендә 18.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр;

– үткәрү урыны -Әлкәй авылы , Совет ур., 34 йорт, Әлкәй авылы мәдәният йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 16 октябреннән дә соңга калмыйча. гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес: Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а буенча

гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә.

- Әлкәй авылы торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Әлкәй торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Әлкәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне ашкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нагорный тыкрыгы буйлап вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, материаллар, җайланмалар сатып алу, торбаларны алмаштыру).;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (стелла сатып алу һәм урнаштыру, үлән чабу, юлларны кардан чистарту).

« РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а йорт (Башкарма комитетның административ бинасы); Әлкәй авылы, Совет урамы, 34 йорт (авыл мәдәният йорты), Совет ур., 2а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Әлкәй авыл җирлеге башлыгы А.Н.Арсланов

АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ... СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1602002494 КПП 164301001